РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы,ул. Пионерская,1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
Советы

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы,Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

22.07.2021 ел　　　　№ 20

Кармалы авыл җирлеге Советының «Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 35 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кармалы авыл җирлеге Советының «Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 35 номерлы карары белән (алга таба – карар) расланган Кармалы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Тәртипнең 3 бүлегендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге башкарма комитеты тора.».

1.2 Тәртипнең 3 бүлегендәге 6 пункты 6.3 пунктчасының 2 абзацын һәм 4 бүлегендәге 3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Совет Кармалинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»

Кармалы авыл җирлеге башлыгы　　　　А.Д. Кубышкин